| ГЛАВА<br>Кадыбашского сельского поселения<br>Агрызского муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы<br>Әгерҗе муниципаль районы<br>Кадыбаш авыл җирлеге<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.10.2019 Кадыбаш авылы № 1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадыбаш авыл җирлеге Кадыбаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадыбаш авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кадыбаш авыл җирлеге башлыгы к а р а р б и р д е:

1.Кадыбаш авыл клубы бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2019 елның 11 октябренә 14 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга: «I төркем инвалидларыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, һәм иректән мәхрүм итү урыннарында булган затлардан тыш, Кадыбаш авыл җирлеге Кадыбаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2020 елда 300 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә сез ризамы:

1.Кадыбаш авылын төзекләндерү, шул исәптән:

- бина һәм корылмаларның тышкы фасадларын, коймаларын төзекләндерү һәм ремонтлау;
- Кадыбаш авылында коелар ремонтлау;
- Кадыбаш авылындагы чишмәне карап тоту һәм ремонтлау;
- Кадыбаш авылындагы агачларны кисү;

- Кадыбаш авылында зиратка илтүче тыкрыктагы юлны көйләү;
- МТЗ-82-1 тракторы өчен гараж ремонтлау.

2. Кадыбаш авылы урамнарын кардан чистарту.

3.Тирән насос сатып алу, су челтәрен ремонтлау өчен җиһазлар сатып алу, Кадыбаш авылындагы суүткәргеч трассасын ремонтлау.

«ӘЙЕ» «ЮК".

3. Кадыбаш авыл җирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Кадыбашского сельского поселения Кадыбаш авыл җирлеге Советы ИНН 1601002572 И.Г. РАМАЗАНОВ